Проект

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә дәүләт йомгаклау аттестациясе**

**Җәмгыять белеме буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларын (КҮМ) үзенчәлекләре (спецификация)**

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде



**Җәмгыять белеме буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларын (КҮМ) үзенчәлекләре**

**1. ТДИ өчен КҮМнең билгеләнеше** – чыгарылыш укучыларын дәүләт йомгаклау аттестацияләве максатларында гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф чыгарылыш укучыларын җәмгыять белеме буенча гомуми белем әзерлеге дәрәҗәсен бәяләргә. Имтихан нәтиҗәләре укучыларны урта мәктәпнең профильле сыйныфларына кабул иткәндә кулланыла ала.

ТДИ «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә үткәрелә.

**2. КҮМнең эчтәлеген билгеләүче документлар**

Имтихан эшенең эчтәлеге Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компоненты белән (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2004 елның 5 мартындагы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми мәгариф дәүләт стандартлары федераль компонентын раслау турында» 1089 номерлы боерыгы) билгеләнә.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

**3. КҮМ структурасын сайлап алуга, эшләүгә якын килү**

ТДИ имтихан эше моделе предметның интеграль характерын чагылдыра: җыеп әйткәндә, биремнәр җәмгыять белеме курсының төп эчтәлек линияләрен, фәнни җәмгыять белеменең төрле өлкәләре база нигезләмәләрен эченә ала.

Контроль объектлары булып белемнәрнең дидактик берәмлекләре һәм Дәүләт мәгариф стандарты федераль компонентында беркетелгән белемнәрне формалаштыру буенча таләпләр тора. Бу җәмгыятьнең барлык өлкәләре һәм база институтлары турында, шәхеснең социаль сыйфатлары хакында һәм аларны формалаштыру шартлары турында, иң мөһим икътисадый күренешләр һәм процесслар хакында, сәясәт, хокук, социаль мөнәсәбәтләр, җәмгыятьнең рухи тормышы турында фәнни осталык, танып-белү ысуллары һәм белемнәрнең киң спектры.

ТДИ өчен КҮМ биремнәре рәвеше һәм катлаулылык дәрәҗәсе буенча аерыла, алар биремнәрне үтәү өчен кирәкле булган танып-белү эшчәнлеге ысуллары белән билгеләнә. КҮМ биремнәрен үтәү мәгълүматны танып-белү, кабатлау һәм алу, классификацияләү, системалаштыру, чагыштыру, аныклау, белемнәрне куллану (үрнәк буенча яки контекстта), аңлату, дәлилләү, бәяләү һ.б. кебек интеллектуаль гамәлләр башкаруны күздә тота. База дәрәҗәсеннән аермалы буларак, югарырак һәм югары катлаулылык дәрәҗәсендәге белемнәр тагын да катлаулы, кагыйдә буларак, үзенең характеры буенча комплекслы танып-белү эшчәнлеген күздә тота.

Предмет спецификасы һәм тулаем социаль-гуманитар белемнәр үзенчәлеге, шулай ук имтихан эшендә кулланылучы мәгълүмат чыганакларын сайлап алганда исәпкә алына. Бу, кагыйдә буларак, социологик тикшеренүләр нәтиҗәсе, фәнни-популяр, социаль-фәлсәфи характердагы басмалардан яраклаштырылган текстлар, хокукый актлардан өземтәләр. Фактларны чагылдыручы фикер йөртүгә һәм бәяләү әйтемнәренә биремнәр өчен, стиле буенча массакүләм мәгълүмат чаралары (ММЧ) хәбәрләренә якын, зур булмаган текстлар эшләнә.

**4. ТДИ имтихан моделенең БДИ КҮМ белән элемтәсе**

ТДИ имтихан моделенең байтак биремнәре үзләренең төре буенча БДИ биремнәренә охшаш. Болай якын килү үзен аклый, чөнки төп һәм өлкән мәктәптә формалаштырылучы белемнәр, эчтәлекнең база компонентлары күпчелек очракта тәңгәл килә. Моннан тыш, белем бирүнең сыйфатын бәяләүнең формалашып

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте
© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

килүче гомумроссия системасында, төп мәктәп чыгарылыш укучыларын дәүләт йомгаклау аттестацияләвен исәпкә алып, болай якын килү дәүләт йомгаклау аттестацияләвенең ике этабы дәвамчанлыгын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Шул ук вакытта ТДИ өчен КҮМ эшләгәндә төп мәктәптә укучыларның танып-белү мөмкинлекләре, аларга куелучы фән буенча уку-укыту эчтәлеге күләме һәм характеры исәпкә алынды. Бу ТДИ имтихан моделе үзенчәлекләрен алдан ук билгеләде. БДИ КҮМнән иң җитди аерма имтихан эшенең 2 бүлегендә күренә, ул мөстәкыйль генә түгел, эчтән дә бөтен бүлекне тәшкил итә: төрле типтагы биремнәрнең барлык алтысы да монда социаль чынбарлыкның мәгълүм бер ягын яктыртучы махсус сайлап алынган текст белән турыдан-туры бәйләнгән.

**5. КҮМ структурасы һәм эчтәлеге характеристикасы**

Ихтихан эше 31 биремне эченә алган ике өлештән тора. 1 өлеш кыска җаваплы 25 биремнән, 2 өлеш киңәйтелгән җаваплы 6 биремнән гыйбарәт.

Эшнең 1-2 биремнәренең һәркайсына дүрт вариант җавап тәкъдим ителә, аларның берсе генә дөрес. Әгәр имтиханда катнашучы дөрес җавап номерын язып куйса,

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

бирем дөрес үтәлгән дип санала. Бирем түбәндәге очракларда үтәлмәгән дип санала:

а) дөрес булмаган җавап номеры язылса; б) ике яки аннан күбрәк җавап номеры язып куелса, хәтта алар арасында дөрес җавап номеры күрсәтелсә дә; в) җавап номеры язылмаса.

21-25 биремнәрдә янәшә һәм аеру символларыннан башка язылган җавап саннар тезмәсе рәвешендә (мәсәлән, 125) бирелә.

2 өлеш биремнәренә җаваплар мөстәкыйль формалаштырыла һәм имтихан тотучы тарафыннан киңәйтелгән рәвештә языла. Аларның үтәлешен тикшерү экспертлар тарафыннан махсус эшләнгән критерийлар нигезендә уздырыла.

Имтихан эше биремнәрен аның өлешләре буенча эшнең һәр өлешен үтәгән өчен башлангыч максималь баллны исәпкә алып бүлү 1 таблицада бирелә.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

*1 нче таблица. Биремнәрне имтихан эше өлешләре буенча бүлү*

| № | Эш өлешләре | Биремнәр төре | Биремнәр саны | Максималь башлангыч балл | Һәр өлешкә максималь башлангыч баллдан процент |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 1 өлеш | Кыска җавап белән | 25 | 26 | 66,7 |
| 2 | 2 өлеш | Киңәйтелгән җавап белән | 6 | 13 | 33,3 |
| | Барлыгы | | 31 | 39 | 100 |

**6. КҮМ биремнәрен эчтәлек, тикшерелүче осталык һәм эшчәнлек ысуллары буенча бүлү**

Эшнең 1 өлешендә:

- 1-20 биремнәр курсның түбәндәге курсларын тәшкил итә: *кеше һәм җәмгыять, рухи мәдәният өлкәсе, икътисад, социаль өлкә, сәясәт һәм социаль идарә өлкәсе, хокук*. Әлеге линияләрне тәшкил иткән биремнәр *биш блок-модуль итеп* төркемләнгән. Кеше һәм җәмгыять, рухи мәдәният өлкәсе бердәй блок-модуль итеп китерелә. Эшнең бу өлешендә бер үк эчтәлек компонентын тикшерүче белемнәр беркетелгән һәм имтихан эшенең һәр вариантында тәңгәл килә;

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



- КҮМнең һәр вариантында 21-25 биремнәр билгеле бер белемнәрне тикшерүгә юнәлтелгән. КҮМнең төрле вариантларында бер үк позициядә катлаулылыкның бер дәрәҗәсе биремнәре бар, алар *эчтәлекнең төрле элементларында* бер үк яки охшаш осталыкны тикшерергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта һәр вариантта 21-25 биремнәрнең һәм 26-31 биремнәрнең аларның берләшүе бер үк блок-модульне тәшкил итүче кушымта урнаштырыла.

Киңәйтелгән җаваплы биремнәр санына (эшнең 2 өлеше) тәкъдим ителгән өзек текстын анализлау белән бәйле алты бирем керә. Эшләр вариантларының барлык комплексына яраклы рәвештә берләшеп, бу текстлар курсның барлык эчтәлек линияләрен эченә ала.

2 нче таблицада имтихан эше биремнәре белән тикшерелүче осталык һәм эшчәнлек ысулы бирелә.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

*2 нче таблица. Биремнәрнең тикшерелүче белемнәр һәм эшчәнлек ысуллары буенча бүленеше*

| № | Тикшерелүче әзерлек дәрәҗәсе элементлары | Бирем-нәр саны | Макси-маль башлан-гыч балл | Тулысынча эш өчен 39 га тигез максималь башлангыч баллдан процент |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Аларның мөһим билгеләрен аерып күрсәтеп, төп социаль объектларны, кешене социаль-эшлекле зат буларак *сурәтләргә*; төп социаль рольләр | 9 | 9 | 23,1 |
| 2 | Социаль объект-ларны, җәмгыять һәм кеше турында фикерләүне чагыштырырга; аларның охшаш якларын һәм аерымлыкларын *ачыкларга* | 3 | 4 | 10,2 |
| 3 | Өйрәнелгән социаль объектларның (җәмгыять һәм табигатьнең, кеше белән җәмгыятьнең, иҗтимагый тормыш өлкәләренең, граждан һәм дәүләтнең үзара эшчәнлеген дә кертеп) үзара хезмәттәшлеген *аңлатырга* | 7 | 8 | 20,5 |
| 4 | Билгеле бер типтагы социаль объектларга, социаль мөнәсәбәт-ләргә; социаль нормалар ярдәмендә җайга салынучы вакыйгаларга; төрле өлкәләрдәге кеше эшчәнлегенә *мисаллар китерергә* | 1 | 3 | 7,7 |
| 5 | Кешенең үз-үзен тотышын социаль нормалардан, икътисадый рациональлектән чыгып *бәяләргә* | 1 | 2 | 5,1 |
| 6 | Өйрәнелгән материаллар нигезендә кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләренә караган | 6 | 7 | 18 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | типик вакыйгаларны чагылдыручы теоретик һәм гамәли биремнәрне *үтәргә* | | | |
| 7 | Бирелгән тема буенча төрле чыганаклардан (ММЧ материаллары, дәреслекләрдән һәм башка яраклаштырылган чыганаклардан) социаль мәгълүмат *эзләүне тормышка ашырырга* | 4 | 6 | 15,4 |
| | Барлыгы | 31 | 39 | 100 |

**7. КҮМ биремнәрен катлаулылык дәрәҗәләре буенча бүлү**

3 нче таблицада имтихан эше биремнәрен катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүлү турында мәгълүмат бирелә.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

*3 нче таблица. Имтихан эше биремнәрен катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүлү*

| Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремнәр саны | Макси-маль башлангыч балл | Тулысынча эш өчен 39 га тигез максималь башлангыч баллдан процент |
|---|---|---|---|
| База | 16 | 18 | 46 |
| Югарырак | 13 | 16 | 41 |
| Югары | 2 | 5 | 13 |
| Барлыгы | 31 | 39 | 100 |

**8. Җәмгыять белеме буенча ТДИның дәвамлылыгы**

Имтихан эшен үтәүгә 3 сәгать (180 минут) бирелә.

**9. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Өстәмә материаллар һәм җиһазлар кулланылмый.

**10. Аерым биремнәрне һәм тулаем имтихан эшен үтәүне бәяләү системасы**

Дөрес эшләнгән эш 39 балл белән бәяләнә.

1-21, 23-25 биремнәрнең һәркайсына дөрес җавап биргән өчен 1 балл куела.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

22 бирем түбәндәге принцип буенча бәяләнә: хата булмаса - 2 балл; бер хата булса – 1 балл; ике һәм аннан да күбрәк хата булганда – 0 балл.

2 өлештәге биремнәр җавапның тулылыгыннан һәм дөреслегеннән чыгып бәяләнә.

26-28, 30 һәм 31 биремнәрне дөрес һәм тулысынча үтәгән өчен 2 балл бирелә. Җавап тулы булмаса – 1 балл.

29 биремне дөрес һәм тулысынча үтәгән өчен 3 балл бирелә. Таләп ителгән җавап компонентларының бирү-бирелмәвенә бәйле рәвештә бирем тулысынча үтәлмәгән очракта – 2 яисә 1 балл.

Шулай итеп, 2 өлештәге биремнәрне үтәгән (барлык алты сорауга да җавапларның дөрес һәм тулы формулировкасы булганда) өчен, имтихан бирүче максималь 13 балл алырга мөмкин.

Төп гомуми белем мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрү тәртибе (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 25 декабрендәге 1394 номерлы боерыгы Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан 2014 елның 3 февралендәге 31206 номерлы карары белән теркәлгән) нигезендә

«48. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә имтихан эшләре биремнәренә

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

җавапларның һәркайсына баллар куя... Ике эксперт куйган баллар арасында җитди аерма булган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Балларда җитди аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан имтихан эшен элек тикшермәгән экспертлар арасыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен элек тикшергән экспертлар куйган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргысы булып тора».

26-31 биремнәрнең теләсә кайсын үтәгән өчен баллар аермасы 2 һәм аннан күбрәк булса, өченче эксперт шундый җитди аермага китергән биремнәрне генә тикшерә.

**11. 2016 ел КҮМендә 2015 ел белән чагыштырганда үзгәреш**

КҮМ эчтәлегендә үзгәрешләр юк.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

*Кушымта*

# ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ буенча IX сыйныф чыгарылыш укучыларын ДЙА (дәүләт йомгаклау аттестацияләве) өчен 2016 ел КҮМ вариантының гомумиләштерелгән планы

*Биремнең катлаулылыгы дәрәҗәләре: Б – база; П – югарырак; В – югары*

| № т/с | Тикшерелүче эчтәлек элементлары | Тикшерелүче эчтәлек элементлары коды | Тикшерелүче осталык коды | Биремнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремне үтәгән өчен максималь балл | Биремне үтәүгә бирелгән якынча вакыт (мин.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1 бүлек** | | | | | | |
| 1 | Кешеләрнең тормыш эшчәнлеге рәвеше буларак җәмгыять; җәмгыятьнең һәм табигатьнең үзара йогынтысы; җәмгыять тормышының төп өлкәләре, аларның үзара бәйләнешы | 1.1-1.3 | 1.2, 1.3, 2.1 | Б | 1 | 1-2 |
| 2 | Кешедә биологик һәм социаль асыл; кешенең эшчәнлеге һәм аның төп формалары (хезмәт, уен, уку); кеше һәм аның иң якындагы тирәлеге; шәхесара мөнәсәбәтләр, аралашу, шәхесара конфликтлар, аларны конструктив хәл итү | 1.4-1.8 | 1.1, 2.1 | Б | 1 | 1-2 |
| 3 | Җәмгыять һәм кеше (социаль чынбарлыкка мөрәҗәгать итүгә бирем) | 1.1-1.8 | 1.1, 1.3, 2.6 | Б | 1 | 1-2 |
| 4 | Җәмгыять һәм кеше (ике төрле фикерне анализлауга бирем) | 1.1-1.8 | 1.1, 1.3, 2.3 | П | 1 | 2-4 |
| 5 | Рухи мәдәният өлкәсе һәм аның үзенчәлекләре; заманча җәмгыять тормышында фән; мәгариф һәм аның мәгълүмати җәмгыять шартларында әһәмияте; Россия Федерациясендә гомуми һәм һөнәри белем алу мөмкинлекләре; дин, дини оешмалар һәм берләшмәләр, заманча җәмгыятьтә аларның роле; вөҗдан иреге; әхлак; гуманлылык; ватанпәрвәрлек; гражданлык | 2.1-2.5 | 2.1, 2.6 | Б | 1 | 1-2 |
| 6 | Рухи тормыш өлкәсе (ике төрле фикерне анализлауга бирем) | 2.1-2.6 | 2.3 | П | 1 | 2-4 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Икътисад һәм аның җәмгыять тормышында роле; товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр, ресурслар һәм ихтыяҗлар, ресурсларның чикләнгән булуы; икътисадый системалар һәм милек; җитештерү, хезмәт җитештерүчәнлеге; хезмәт бүленеше һәм спецификациясе; алмашу, сәүдә; базар һәм базар механизмы | 3.1-3.6 | 2.1 | Б | 1 | 1-2 |
| 8 | Эшкуарлык; кече эшкуарлык һәм хосусый хезмәт эшчәнлеге; акча; хезмәт хакы һәм эшкә стимуллаштыру; керемнәрнең тигез булмавы һәм социаль ярдәм күрсәтүнең икътисадый чаралары; граждан тарафыннан түләнүче салымнар; дәүләтнең икътисадый максатлары һәм функцияләре | 3.7-3.12 | 2.1 | Б | 1 | 1-2 |
| 9 | Җәмгыять тормышының икътисадый өлкәсе (социаль чынбарлыкка мөрәҗәгать итүгә бирем) | 3.1-3.12 | 2.6 | Б | 1 | 1-2 |
| 10 | Җәмгыять тормышының икътисадый өлкәсе (ике төрле фикерне анализлауга бирем) | 3.7-3.12 | 2.3 | П | 1 | 2-4 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 11 | Җәмгыятьнең социаль структурасы, кечкенә төркем буларак гаилә, яшүсмерлек чорында социаль рольләрнең күптөрлелеге, тәртипкә начар йогынты ясаучы социаль кыйммәтләр һәм нормалар, социаль конфликт һәм аны чишү юллары, милләтара мөнәсәбәтләр | 4.1-4.6 | 2.1 | Б | 1 | 1-2 |
| 12 | Социаль өлкә (социаль чынбарлыкка мөрәҗәгать итүгә бирем) | 4.1-4.6 | 2.6 | Б | 1 | 1-2 |
| 13 | Социаль өлкә (ике төрле фикерне анализлауга бирем) | 4.1-4.6 | 2.3 | П | 1 | 2-4 |
| 14 | Хакимият; җәмгыять тормышында сәясәтнең роле; дәүләт төшенчәсе һәм аның билгеләре; хакимият бүленеше; дәүләт формалары; сәяси режим; демократия; җирле үзидарә; гражданнарның сәяси тормышка катнашуы; сайлаулар, референдум; сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, аларның җәмгыять тормышында роле; граждан җәмгыяте һәм хокукый дәүләт | 5.1-5.10 | 2.1 | Б | 1 | 1-2 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Сәясәт өлкәсе һәм социаль идарә (социаль чынбарлыкка мөрәҗәгать итүгә бирем) | 5.1-5.10 | 2.6 | Б | 1 | 1-2 |
| 16 | Сәясәт өлкәсе һәм социаль идарә (ике төрле фикерне анализлауга бирем) | 5.1-5.10 | 2.3 | П | 1 | 2-4 |
| 17 | Хокук, аның җәмгыять һәм дәүләт тормышында роле; хокук нормасы; норматив хокукый акт; хокук бозуларның төрләре һәм билгеләре; юридик җаваплылык төшенчәсе һәм төрләре; административ хокукый мөнәсәбәтләр, хокук бозулар һәм җәзага тарту; җинаятькә каршы көрәш хокукы төп төшенчәләре һәм институтлары; балигъ булмаганнарны җинаять җаваплылыгына тарту | 6.1, 6.2, 6.4, 6.16, 6.17 | 2.1 | Б | 1 | 1-2 |
| 18 | РФ Конституциясе; РФнең конституциячел строе нигезләре; Россиянең федератив корылышы; РФнең дәүләт хакимияте органнары; хокук саклау органнары; суд системасы; дәүләт хакимияте органнары һәм гражданнарның үзара мөнәсәбәтләре; Россиядә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре; аларның гарантияләре; гражданның конституциячел бурычлары; бала хокуклары һәм аларны яклау; балигъ булмаганнарның хокукый статусы үзенчәлекләре; кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау һәм тормышка ашыру механизмнары; кораллы конфликтлар корбаннарын халыкара-хокукый яклау | 6.5-6.12 | 2.1 | Б | 1 | 1-2 |
| 19 | Хокукый мөнәсәбәтләр төшенчәсе, хезмәткә хокук һәм хезмәттә хокукый мөнәсәбәтләр, балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру, гаиләдә хокукый мөнәсәбәтләр, ата-аналар һәм балаларның хокуклары һәм бурычлары, гражданлык хокукый мөнәсәбәтләре, милек хокукы, кулланучылар хокукы (социаль чынбарлыкка мөрәҗәгать итүгә бирем) | 6.3, 6.13-6.15 | 2.6 | Б | 1 | 1-2 |
| 20 | Хокук (ике төрле фикерне анализлауга бирем) | 6.1-6.17 | 2.3 | П | 1 | 2-4 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | Төрле вариантларда төрле эчтәлек: бирем тикшерелә торган осталыкка юнәлтелгән (чагыштыруга бирем) | - | 2.2 | П | 1 | 7-10 |
| 22 | Төрле вариантларда төрле эчтәлек: бирем тикшерелә торган осталыкка юнәлтелгән (тәңгәллекне билгеләүгә бирем) | - | 2.2, 2.3 | Б | 2 | 7-10 |
| 23 | Төрле вариантларда төрле эчтәлек: бирем тикшерелә торган осталыкка юнәлтелгән (исемлектән дөрес позицияне сайлап алуга бирем) | - | 2.3, 2.7 | П | 1 | 7-10 |
| 24 | Төрле вариантларда төрле эчтәлек: бирем тикшерелә торган осталыкка юнәлтелгән (исемлектән дөрес позицияне сайлап алуга бирем) | - | 2.3, 2.7 | П | 1 | 7-10 |
| 25 | Төрле вариантларда төрле эчтәлек: бирем тикшерелә торган осталыкка юнәлтелгән (фактлар һәм фикерләр ачыклауга бирем) | - | 2.2, 2.3 | П | 1 | 5-7 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җәмгыять белеме. 9 сыйныф

| 2 өлеш | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 26 | Төрле вариантларда төрле эчтәлек: бирем тикшерелә торган осталыкка юнәлтелгән (чыганакларга анализ ясауга бирем) | – | 2.7 | П | 2 | 20-25 |
| 27 | | – | 2.7 | Б | 2 | 8-10 |
| 28 | | – | 2.3, 2.7 | П | 2 | 8-10 |
| 29 | | – | 2.3, 2,4, 2,7 | В | 3 | 15-20 |
| 30 | | – | 2.3, 2.6, 2.7 | П | 2 | 8-10 |
| 31 | | – | 2.3, 2.5, 2.7 | В | 2 | 10-15 |
| Барлыгы **31** бирем; шуларның<br>бирем төре буенча: кыска җавап белән – **25**, киңәйтелгән җавап белән – **6**;<br>катлаулылык дәрәҗәсе буенча: Б – **16**, П – **13**, В – **2**.<br>Башлангыч максималь балл – **39.**<br>Биремне үтәү өчен бирелгән гомуми вакыт – **180 минут.** | | | | | | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте